**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА СУМАРОКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КЫРЫК ИКЕНЧЕ СЕССИЯ**

# КАРАР № 3

Яңа Сумароково авылы 20 май 2019 ел

**«Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**«Яңа Сумароково авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегендә муниципаль**
**хезмәт турындагы Нигезләмә турында»**
**2017 елның 3 июлендә кабул ителгән**
**Яңа Сумароково авыл җирлеге Советының**
**XXI сессиясенең №2 карарына**
**үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 октябрендәге №382-ФЗ Федераль законнарга таянып, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законның 7 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге №559-ФЗ һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 маддәсенә, шулай ук муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге №50-ТРЗ Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә

## Яңа Сумароково җирлеге Советы

## КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә турында» 2017 елның 3 июлендә кабул ителгән Яңа Сумароково авыл җирлеге Советының XXI сессиясенең №2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. *13 маддәне яңа 4 һәм 5 бүлекләр белән тулыландырырга:*

«4. Гражданин «Яңа Сумароково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы (Башкарма комитеты җитәкчесе) белән якын туганлыкта булганда (ата-анасы, хатыны, балалары, бертуганнар, сеңелләре, абыйлары шулай ук, иренең яки хатынының ата-анасы, бертуганнары, сеңелләре, балалары) муниципаль берәмлекнең тикшерү-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы

вазыйфасына, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлекнең тикшерү-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфасына билгеләнә алмый.

5. Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр әлеге вазыйфаны биләгән чорда җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарә органының сайлау профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмый.».

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**«Яңа Сумароково авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **С.Л.Минханова**